# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Минзәлә муниципаль районы Кадрәк авыл җирлегенең
Җәмәк торак пунктында 2024 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

**29.11.2023 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Минзәлә муниципаль районы Кадрәк авыл җирлегенең Җәмәк торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Кадрәк авыл җирлеге Җәмәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2024 елда 2500 сум күләмендә үзсалым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, армиядә хезмәт итүчечеләр, мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) *Җәмәк торак пунктында зиратның коймасын ремонтлау(килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);*
2) *Җәмәк торак пунктында авыл клубы территориясен төзекләндерү (керү юлларын ремонтлау, койма урнаштыру, профильле торбалар һәм евроштакетниклар сатып алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);*
3) *Җәмәк торак пунктында санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү, бурлау (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);*
4) *Җәмәк торак пунктында юлларны грейдирлау (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);*
5) *Җәмәк торак пунктында МТЗ-82 тракторына хезмәт күрсәтү (запчастьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәт хакы).*

3. Җыенның нәтиҗәләрен Кәдрәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән, халык җыенының нәтиҗәләрен Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга(https://menzelinsk.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән соң ун көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Кадрәк авыл җирлеге башлыгы ______________ Х. Х. Нәбиуллин
(имза)